ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.12,
с.Старый Каразерик, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 12 йорт,
Иске Каразирек авылы, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

---

Карар | Постановление
№9 | 13.06.2023

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 апрелендәге 7 санлы карары белән расланган “Муниципаль берәмлектә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2019 елның 22 июнендәге «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында»гы 796 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Иске Каразирек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 апрелендәге 7 санлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Тәртипнең 12 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ташламаларга хокуктан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламаны куллануга потенциаль хокукы булган түләүчеләр санының 5 ел эчендә түләүчеләрнең гомуми санының нисбәте белән характерлана торган ташламаларны түләүчеләргә ихтыяҗ булу»;

1.3. 3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Үз көчен югалткан дип түбәндәгеләрне танырга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районыИске Каразирекавыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 апрелендәге 13 санлы карары белән расланган “Муниципаль берәмлектә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районыИске Каразирекавыл җирлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»гы 8 санлы карарын;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске

Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Каразирек
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Вәлиев